| | |
|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 гыйнвар № 24

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 июль, 470 нче; 2014 ел, 30 декабрь, 1062 нче һәм 2015 ел, 17 август, 604 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме, беренчел исәп-хисаплар буенча 18 281 965,27 мең сум тәшкил итә, шулардан:<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 60 000,0 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 18 221 965,27 мең сум.<br><br>Программаны еллар буенча финанслауның гомуми күләме:<br>2014 ел – 2 654 730,72 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 30 000,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 2 624 730,72 мең сум;<br>2015 ел – 2 527 832,81 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 30 000,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 2 497 832,81 мең сум;<br>2016 ел – 2 427 147,7 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 427 147,7 мең сум;<br>2017 ел – 2 507 836,19 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 507 836,19 мең сум;<br>2018 ел – 2 617 838,25 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 617 838,25 мең сум;<br>2019 ел – 2 722 915,79 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 722 915,79 мең сум;<br>2020 ел – 2 823 663,81 мең сум, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 823 663,81 мең сум.<br>Ярдәмче программалар буенча финанслауның гомуми күләме:<br>«2014 – 2020 елларга мәгълүмати Татарстан» ярдәмче программасы – 4 413 366,69 мең сум;<br>«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасы – 4 241 631,13 мең сум;<br>«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмати киңлек инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү» ярдәмче программасы – 8 832 157,24 мең сум;<br>«2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү» ярдәмче программасы – 794 810,21 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фараз характеренда була |

| | |
|---|---|
| | һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш»; |

«Еллар буенча бүлеп, Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының унҗиденче абзацын төшереп калдырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме беренчел исәп-хисаплар буенча 18 281 965,27 мең сум тәшкил итә, шулардан:

җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 60 000,0 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 18 221 965,27 мең сум.

1 таблица

Ярдәмче программалар һәм еллар буенча Программаны финанслау күләме

(мең сум)

| Ярдәмче программа исеме | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 2014 – 2020 елларга мәгълүмати Татарстан, шулардан: | 644 534,59 | 669 628,19 | 618 440,0 | 581 746,14 | 609 507,72 | 632 798,11 | 656 711,94 | 4 413 366,69 |
| җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,0 | 30 000,0 | - | - | - | - | - | 60 000,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 614 534,59 | 639 628,19 | 618 440,0 | 581 746,14 | 609 507,72 | 632 798,11 | 656 711,94 | 4 353 366,69 |
| 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын үстерү, шулардан: | 685 173,9 | 569 956,08 | 566 413,2 | 569 612,98 | 593 524,91 | 617 305,04 | 639 645,02 | 4 241 631,13 |
| 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү, шулардан: | 127 994,23 | 102 291,14 | 95 551,4 | 110 224,81 | 114 964,48 | 119 678,03 | 124 106,12 | 794 810,21 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 127 994,23 | 102 291,14 | 95 551,4 | 110 224,81 | 114 964,48 | 119 678,03 | 124 106,12 | 794 810,21 |
| БАРЛЫГЫ, шулардан: | 2 654 730,72 | 2 527 832,81 | 2 427 147,7 | 2 507 836,19 | 2 617 838,25 | 2 722 915,79 | 2 823 663,81 | 18 281 965,27 |
| җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,0 | 30 000,0 | - | - | - | - | - | 60 000,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 2 624 730,72 | 2 497 832,81 | 2 427 147,7 | 2 507 836,19 | 2 617 838,25 | 2 722 915,79 | 2 823 663,81 | 18 221 965,27 |

Программаны финанслау күләме фараз характеренда була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш.

Программаны озак вакытлы чорга финанслау күләмнәрен исәпләү 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеш фаразы инфляциясе индекслары нигезендә башкарылды.

2 таблица

Бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр һәм еллар буенча Программаны финанслау күләме

(мең сум)

| Бюджет акчасы белән баш эш итүче | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, шулардан: | 1 457 702,72 | 1 341 875,41 | 1 280 404,6 | 1 261 583,93 | 1 317 997,11 | 1 369 781,18 | 1 420 463,08 | 9 449 808,03 |
| җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,0 | 30 000,0 | - | - | - | - | - | 60 000,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 1 427 702,72 | 1 311 875,41 | 1 280 404,6 | 1 261 583,93 | 1 317 997,11 | 1 369 781,18 | 1 420 463,08 | 9 389 808,03 |
| Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, шулардан: | 1 197 028,0 | 1 185 957,4 | 1 146 743,1 | 1 246 252,26 | 1 299 841,14 | 1 353 134,61 | 1 403 200,73 | 8 832 157,24 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 1 197 028,0 | 1 185 957,4 | 1 146 743,1 | 1 246 252,26 | 1 299 841,14 | 1 353 134,61 | 1 403 200,73 | 8 832 157,24»; |

«2014 – 2020 елларга мәгълүмати Татарстан» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме беренчел исәп-хисаплар буенча 4 413 366,69 мең сум |

| | |
|---|---|
| программаны финанслау күләмнәре | тәшкил итә, шулардан:<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 60 000,0 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 4 353 366,69 мең сум.<br>Ярдәмче программаны еллар буенча финанслауның гомуми күләме:<br>2014 ел – 644 534,59 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 30 000,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 614 534,59 мең сум;<br>2015 ел – 669 628,19 мең сум, шулардан федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча исәбеннән – 30 000,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 639 628,19 мең сум;<br>2016 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан 618 440,0 мең сум;<br>2017 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан 581 746,14 мең сум;<br>2018 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан 609 507,72 мең сум;<br>2019 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан 632 798,11 мең сум;<br>2020 ел – Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан 656 711,94 мең сум.<br>Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характеренда була һәм чираттагы елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш»; |

«Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ярдәмче программаны тормышка ашыру процессында 2020 ел ахырына түбәндәге күрсәткечләргә ирешү планлаштырыла:<br>күрсәтелгән хезмәтләрнең гомуми санында дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү фактлары өлеше – 70 процент;<br>универсаль белгечләре булган, «бер тәрәзә» режимында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль |

| | |
|---|---|
| | хезмәтләр күрсәтү буенча гамәлдәге күпфункцияле үзәкләрнең (КФҮ) гомуми санында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә документлар бирү өчен автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан (АМС) файдаланучы Татарстан Республикасының КФҮ өлеше – 100 процент;<br>«ЗАГС» АМС файдаланучы, граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре йөкләнгән җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өлеше – 100 процент;<br>аларга язылу электрон чираттан файдаланып гамәлгә ашырылырга мөмкин булган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өлеше – 100 процент;<br>мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып алынган балалар өлеше – 100 процент;<br>«Татарстан Республикасында электрон мәгариф» мәгълүмат системасыннан файдаланучылар саны – 1 000 мең кеше;<br>файдаланучыларны «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында эшләргә укыту-өйрәтү буенча үткәрелгән кеше-сәгать саны– 240 мең кеше × ак.сәгать;<br>автоматлаштырылган китапханә мәгълүмат системасына (АКМС) тоташтырылган һәркем файдалана алырлык үзәк китапханәләр өлеше – 100 процент;<br>автоматлаштырылган китапханә мәгълүмат системасына (АКМС) тоташтырылган һәркем файдалана алырлык үзәк китапханәләрнең филиаллары өлеше – 24 процент;<br>Татарстан Республикасы китапханәләренең җыелма электрон каталогында библиографик язмалар саны – 650 мең берәмлек;<br>электрон рәвешкә күчерелгән тарихи басмалар өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасының эш белән тәэмин итү органнарында эшкә урнашуга мохтаҗ дип саналган, эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү буенча автоматлаштырылган мәгълүмат системасында исәпкә алынган гражданнар өлеше – 95 процент;<br>«Татарстан Республикасында социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаган- |

| | |
|---|---|
| | нарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасына кертелгән Татарстан Республикасында социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны тикшерү актлары өлеше – 100 процент;<br>мәгълүмат системасында теркәлгән мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне тернәкләндерү программалары өлеше – 80 процент;<br>пациентларның гомуми санында электрон медицина карталары алып барылган пациентлар өлеше – 100 процент;<br>«Татарстан Республикасы Электрон сәламәтлек саклау» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган медицина оешмалары өлеше – 100 процент;<br>«Капиталь ремонтлау буенча дәүләт программасы үтәлешен формалаштыру һәм мониторинглау һәм торак фонды объектлары торышын мониторинглау» мәгълүмат-аналитика системасында капиталь ремонтлау объектлары буенча еллык финанслауны үзләштерү өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланучылар сораткан һәм «Коммуналь түләүләр» кулланма программалар пакеты веб-сервислары тарафыннан эшкәртелгән мөрәҗәгатьләр өлеше – 100 процент;<br>«Ачык Татарстан» порталында шәхси кабинетлары булган гражданнар өлеше (гражданнарның гомуми санында) – 60 процент;<br>«Тикшерү-күзәтчелек эшчәнлеге мониторингы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылырга тиешле органнарның гомуми санында әлеге системага тоташтырылган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өлеше – 100 процент;<br>«Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү» дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылырга тиешле органнарның гомуми санында әлеге системага тоташтырылган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өлеше – 100 процент;<br>гамәлдәге законнарда каралган хисапларның гомуми санында «Татарстан Республикасының Агро-сәнәгать комплексы» мәгълүмат-аналитика системасында электрон рәвештә формалаштырылган хисаплар |

| | |
|---|---|
| | өлеше – 100 процент;<br>электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасына тоташтырылган оешмалар адресына электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә җибәрелгән чыга торган документларның гомуми санында дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре тарафыннан электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында электрон рәвештә эшләнгән һәм имзаланган, электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасына тоташтырылган оешмаларга адресланган чыга торган документлар өлеше – 75 процент;<br>расланган дәүләт программаларының гомуми санында Максатчан программалар белән идарә итү буенча дәүләт автоматлаштырылган системасына кертелгән Татарстан Республикасының дәүләт программалары өлеше – 100 процент;<br>социаль яктан әһәмиятле тармакларда ведомстволар карамагындагы бюджет учреждениеләре челтәре эшчәнлеген мониторинглау буенча мәгълүмат-аналитика системасы ярдәмендә ведомстволар карамагындагы оешмалардан мәгълүмат җыючы Татарстан Республикасы министрлыклары өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә хуҗалыкларны исәпкә алу буенча мәгълүмат системасында электрон хуҗалык кенәгәсен формалаштыру өчен җитәрлек мәгълүматы булган хуҗалыклар өлеше – 100 процент;<br>Бюджет исәбе һәм хисаплылык мәгълүмат системасы ярдәмендә бюджет хисаплылыгын тапшыра торган дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр өлеше – 100 процент;<br>дәүләт ихтыяҗларында һәм муниципаль ихтыяҗларда заказларны электрон рәвештә формалаштыру, килештерү һәм урнаштыруны гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр өлеше – 100 процент;<br>дәүләт учреждениеләрен һәм муниципаль учреждениеләрне норматив финанслауны, Татарстан Республикасында дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан хезмәтләр күрсәтү |

| | |
|---|---|
| | һәм карап тотуга бюджет ихтыяҗын исәпләү буенча мәгълүмат-аналитика системасында дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен формалаштырган дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр өлеше – 100 процент;<br>салым хисаплылыгын һәм хисаплылыкның башка төрләрен электрон рәвештә тапшыра торган дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр өлеше – 100 процент;<br>бердәм программалар комплексы кысаларында бюджетларның казначылык үтәлеше өлешендә хезмәтләр күрсәтелә торган дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр өлеше – 100 процент;<br>капитал кертемнәренең дәүләт программасын үтәүне формалаштыру һәм мониторинглау, капиталь төзелеш һәм төзекләндерү объектлары торышын мониторинглау буенча мәгълүмат-аналитика системасына тикшерүгә кертелгән башкарылган эшләр актлары өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан гамәлгә ашырыла торган тикшерү һәм күзәтчелек процессын автоматлаштыру буенча электрон мәгълүмат системасына кертелгән төзелеш өлкәсендә хокук бозулар турындагы беркетмәләр өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланучы Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләре хезмәткәрләре өлеше – 100 процент;<br>«Украина территориясеннән китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарның бердәм мәгълүматлар базасы» мәгълүмат системасына Украина территориясеннән китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнар турында мәгълүмат кертергә техник мөмкинлеге булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өлеше – 100 процент;<br>Россия Федерациясе субъектларының гомуми санында «Татарстан Республикасы товарларын тышкы базарларга чыгару» мәгълүмат-аналитика |

| | |
|---|---|
| | системасын кулланып, «Татарстан Республикасы товарларын тышкы базарларга чыгару» тикшеренүе кысаларында булган Россия Федерациясе субъектлары өлеше – 90 процент;<br>алкоголь продукциясе әйләнеше буенча декларация ясарга тиешле оешмаларның гомуми санында «Алкоголь инспекциясе» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат-аналитика системасында шәхси кабинет аша декларацияләр бирүче оешмалар өлеше – 100 процент;<br>«Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм тикшерүдә тоту системасы» дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылырга тиешле органнарның гомуми санында әлеге системага тоташтырылган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасы халкының гомуми санында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы базасында «112» бердәм номеры буенча кичектергесез-оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү системасы киң таралган муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче Татарстан Республикасы халкы өлеше – 100 процент;<br>«ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасында контрольдә булган мәктәп транспорт чаралары саны – 700 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының геопорталында урнаштырылган киңлек мәгълүматларыннан файдаланучы Татарстан Республикасы министрлыклары өлеше – 100 процент;<br>төбәк дәрәҗәсендәге табигатьтән файдаланучыларга бирелгән зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең атмосфера һавасына чыгарылуына рөхсәтнамәләрнең гомуми санында «Электрон экология» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелгән, төбәк дәрәҗәсендәге табигатьтән файдаланучыларга бирелгән зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең атмосфера һавасына чыгарылуына рөхсәтнамәләр өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасы Экология министрлыгы тарафыннан кабул ителгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары калдыкларының барлыкка килүе, файдаланылуы, зарарсызландырылуы һәм урнаштырылуы |

| | |
|---|---|
| | турындагы хисапларның гомуми санында «Электрон экология» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелгән, Татарстан Республикасы Экология министрлыгы тарафыннан кабул ителгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары калдыкларының барлыкка килүе, файдаланылуы, зарарсызландырылуы һәм урнаштырылуы турындагы хисаплар өлеше – 100 процент;<br>«Электрон экология» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып бирелгән әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү исәпләре өлеше – 65 процент;<br>Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының квалификацияләрен күтәргән мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен җаваплы хезмәткәрләре өлеше – 100 процент;<br>Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вируслардан саклау чарасы белән тәэмин ителгән автоматлаштырылган эш урыннары саны – 9 000 берәмлек;<br>Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының лицензияләнгән автоматлаштырылган эш урыннары саны – 5 700 берәмлек.<br><br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруны бәяләү индикаторлары Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.»; |

ярдәмче программаның бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме беренчел исәп-хисаплар буенча 4 413 366,69 мең сум тәшкил итә, шулардан:

җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 60 000,0 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 4 353 366,69 мең сум.

1 таблица

Ярдәмче программаны еллар буенча финанслау күләме

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Финанслауның гомуми күләме, | 644 534,59 | 669 628,19 | 618 440,0 | 581 746,14 | 609 507,72 | 632 798,11 | 656 711,94 | 4 413 366,69 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| шулардан: | | | | | | | | |
| җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,0 | 30 000,0 | - | - | - | - | - | 60 000,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | 614 534,59 | 639 628,19 | 618 440,0 | 581 746,14 | 609 507,72 | 632 798,11 | 656 711,94 | 4 353 366,69 |

Ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характеренда була һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнергә тиеш.

Ярдәмче программаны озак вакытлы чорга финанслау күләмнәрен исәпләү 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеш фаразы инфляциясе индекслары нигезендә башкарылды.»;

ярдәмче программаның IV бүлегенә түбәндәге эчтәлекле яңа кырык җиденче – кырык тугызынчы абзацлар өстәргә:

«Тикшерү-күзәтчелек эшчәнлеге мониторингы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы;

«Алкоголь инспекциясе» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы;

«Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм тикшерүдә тоту системасы» дәүләт мәгълүмат системасы.»;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-коммуникация инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре» юлында:

беренче абзацта «4 184 574,49» саннарын «4 241 631,13» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «534 662,69» саннарын «569 956,08» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «544 649,95» саннарын «566 413,2» саннарына алмаштырырга;

ярдәмче программаның III бүлегендә:

беренче абзацта «4 184 574,49» саннарын «4 241 631,13» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «534 662,69» саннарын «569 956,08» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «544 649,95» саннарын «566 413,2» саннарына алмаштырырга;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының мәгълүмати киңлек инфраструктурасын үстерү һәм камилләштерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре» юлында:

беренче абзацта «8 781 906,44» саннарын «8 832 157,24» саннарына

алмаштырырга;

өченче абзацта «1 141 555,5» саннарын «1 185 957,4» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1 140 894,2» саннарын «1 146 743,1» саннарына алмаштырырга;

«Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында:

икенче абзацта «2 000» саннарын «2 100» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «1 500» саннарын «1 400» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «13 000» саннарын «14 000» саннарына алмаштырырга;

бишенче абзацта «8 000» саннарын «7 000» саннарына алмаштырырга;

ярдәмче программаның III бүлегендә:

беренче абзацта «8 781 906,44» саннарын «8 832 157,24» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «1 141 555,5» саннарын «1 185 957,4» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1 140 894,2» саннарын «1 146 743,1» саннарына алмаштырырга;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге икътисадый мохитне һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре» юлында:

беренче абзацта «797 425,87» саннарын «794 810,21» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «95 181,4» саннарын «102 291,14» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «105 276,8» саннарын «95 551,4» саннарына алмаштырырга;

ярдәмче программаның III бүлегендә:

беренче абзацта «797 361,08» саннарын «794 810,21» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «95 181,4» саннарын «102 291,14» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «105 276,8» саннарын «95 551,4» саннарына алмаштырырга;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\24.doc

«2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасына кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2016 ел, 19 гыйнвар, 24 нче карары редакциясендә)

**«2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, чаралары буенча финанслау**

| Максат исеме | Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | Финанслау чыганаклары | Финанслау, мең сум | | | | | | | БАРЛЫГЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2013 ел (базf) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
| **«2014 – 2020 елларга мәгълүмати Татарстан» ярдәмче программасы** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. Хезмәт күрсәтү дәрәҗәсен, дәүләт хезмәтләренең, муниципаль һәм социаль әһәмияттәге хезмәтләрнең сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын күтәрү | 1.1. Дәүләт хезмәтләрен, муниципаль һәм социаль әһәмияттәге хезмәтләрне электрон рәвештә алу, шулай ук автомат-лаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, КФҮ базасында «бер тәрәзә» режимында хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итү | 1.1.1. Дәүләт хезмәтләрен, муниципаль һәм социаль әһәмияттәге хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерүне оештыру, шулай ук КФҮ мәгълүмат инфраструктурасын булдыру | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү фактлары өлеше (күрсәтелгән хезмәтләрнең гомуми санында), % | 25 | 35 | 40 | 50 | 60 | 70 | 70 | 70 | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 30 000,00 | 10 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 40 000,00 |
| | | | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Икътисад министрлыгы, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2014 – 2020 еллар | Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә документлар бирү өчен автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланучы Татарстан Республикасының КФҮ өлеше (универсаль белгечләре булган гамәлдәге күпфункцияле үзәкләрнең (КФҮ) гомуми санында), % | 0 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | | | | |
| | | | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР МК каршындагы ГХАЯИ | 2014 – 2020 еллар | «ЗАГС» АМС файдаланучы, граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре йөкләнгән җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы бюджеты | 132 614,64 | 127 541,13 | 148 066,34 | 162 617,65 | 169 610,21 | 176 564,23 | 183 097,10 | 1 100 111,30 |
| | | | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | Аларга язылу электрон чираттан файдаланып гамәлгә ашырылырга мөмкин булган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | | | | |
| | | | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, алынган балалар өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | | | | |
| | 1.2. Социаль өлкә тармакларында мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кертү | 1.2.1. Мәгариф өлкәсендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен үстерү һәм эксплуатацияләү | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» мәгълүмат системасыннан файдаланучылар саны, мең кеше | 900 | 970 | 1 000 | 1 000 | 1 000 | 1 000 | 1 000 | 1 000 | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | 0,00 | 10 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 10 000,00 |
| | | | | | Файдаланучыларны «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында эшләргә укыту-өйрәтү буенча үткәрелгән кеше-сәгать саны, мең кеше х ак.сәгать | 130 | 240 | 240 | 240 | 240 | 240 | 240 | 240 | Татарстан Республикасы бюджеты | 55 036,91 | 54 101,26 | 76 878,42 | 62 246,79 | 65 504,84 | 68 744,93 | 71 788,80 | 454 301,95 |
| | | 1.2.2. Мәдәният өлкәсендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен үстерү һәм эксплуатацияләү | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Мәдәният министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | Автоматлаштырылган китапханә мәгълүмат системасына тоташтырылган һәркем файдалана алырлык үзәк китапханәләр өлеше, % | 65 | 83 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы бюджеты | 16 618,01 | 11 831,41 | 8 586,70 | 19 891,22 | 20 746,54 | 21 597,15 | 22 396,24 | 121 667,27 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Автоматлаштырылган китапханә мәгълүмат системасына тоташтырылган һәркем файдалана алырлык үзәк китапханәләрнең филиаллары өлеше, % | 3 | 6 | 9 | 12 | 15 | 18 | 21 | 24 | | | | | | | | | |
| | | | | | Татарстан Республикасы китапханәләренең җыелма электрон каталогында библиографик язмалар саны, мең берәмлек | 572 | 582 | 592 | 605 | 615 | 625 | 640 | 650 | | | | | | | | | |
| | | | | | Электрон рәвешкә күчерелгән тарихи басмалар өлеше, % | 40 | 50 | 60 | 70 | 80 | 90 | 100 | 100 | | | | | | | | | |
| | | 1.2.3. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен үстерү һәм эксплуатацияләү | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Хезмәт министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | Татарстан Республикасының эш белән тәэмин итү органнарында эшкә урнашуга мохтаҗ дип саналган, эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү буенча автоматлаштырылган мәгълүмат системасында исәпкә алынган гражданнар өлеше, % | 0 | 0 | 80 | 95 | 95 | 95 | 95 | 95 | Татарстан Республикасы бюджеты | 31 793,36 | 35 899,30 | 24 149,37 | 10 945,89 | 11 416,56 | 11 884,64 | 12 324,37 | 138 413,49 |
| | | | | | «Татарстан Республикасында социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасына кертелгән Татарстан Республикасында социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны тикшерү актлары өлеше, % | 0 | 55 | 60 | 65 | 70 | 80 | 90 | 100 | | | | | | | | | |
| | | | | | «Инвалидларның мәгълүматлар базасы» мәгълүмат системасында теркәлгән мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне тернәкләндерү программалары өлеше, % | 0 | 10 | 25 | 40 | 60 | 80 | 80 | 80 | | | | | | | | | |
| | | 1.2.4. Сәламәтлек саклау өлкәсендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен үстерү һәм эксплуатацияләү | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы | 2014 – 2020 еллар | Пациентларның гомуми санында электрон медицина карталары алып барылган пациентлар өлеше, % | 40 | 45 | 50 | 55 | 80 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы бюджеты | 47 247,13 | 56 814,89 | 49 132,94 | 71 610,73 | 74 689,99 | 77 752,28 | 80 629,11 | 457 877,07 |
| | | | | | «Татарстан Республикасы Электрон сәламәтлек сак-лау» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган медицина оешмалары өлеше, % | 0 | 40 | 60 | 80 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | | | | |
| | | 1.2.5. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен үстерү һәм эксплуатацияләү | ТР Мәгълүмат-лаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы, ТР ДТИ | 2014 – 2020 еллар | Капиталь ремонтлау буенча дәүләт программасы үтәлешен формалаштыру һәм мониторинглау һәм торак фонды объектлары торышын мониторинглау мәгълүмат-аналитика системасында капиталь ремонтлау объектлары буенча еллык финанслауны үзләштерү өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы бюджеты | 31 753,41 | 7 483,41 | 7 559,00 | 8 302,07 | 8 659,06 | 9 014,08 | 9 347,60 | 82 118,63 |
